Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының өченче утырышы

Богородский авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

24 ноябрь, 2025 ел № 8

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Богородский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Богородский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 45 номерлы карары белән (2023 елның 31 мартындагы 68, 2023 елның 30 октябрендәге 84, 2023 елның 11 декабрендәге 88, 2024 елның 19 апрелендәге 96, 2024 елның 19 ноябрендәге 114 номерлы үзгәрешләре белән) расланган, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 33 статьяның 1 өлешендәге һәм 8 статьяның 3 өлешендәге 9 пунктында «составы һәм сроклары» сүзләрен «формалаштыру тәртибе, составы һәм сроклары» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 32 статьяның 2 пунктындагы бишенче абзацында «һәм гамәлгә ашырганда» сүзләрен «, дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны үзәкләштерү һәм гамәлгә ашырганда бюджет акчаларын экономияләү нәтиҗәсендә барлыкка килү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы Д.Ю. Булыгин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000835